ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» февраль 2025 ел № 148

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килешү комиссиясен төзү турында**

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе турында» 2015 елның 20 мартындагы 177 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы кадастр эшләрен оештыру турында» 2020 елның 31 мартындагы 237 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча Килештерү комиссиясе төзергә һәм раслarга(килешү буенча).

2. Әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча Килештерү комиссиясенең эш регламентын расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телкоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан соң үз көченә керә, дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.М. Гатиятов

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитеты
Карарына
21.05.2025 ел, № 148
1нче Кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча
Килештерү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Гатиятов Р.М | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Сиразиев И.Г. | Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары |
| Ибрагимова А.А. | Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы баш белгече, комиссия сәркатибе |
| Комиссия әгъзалары | |
| Галимуллин И.А. | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Хасанов И.М. | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе |
| Киямов А.А. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары (килешү буенча) |
| Хайрутдинов А.М | Татарстан Республикасында һәм Ульяновск өлкәсендә дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча федераль агентлыкның төбәкара территориаль идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шакирова Р.Г. | Татарстан Республикасы буенча дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Арча территориаль бүлеше җитәкчесе (килешү буенча) |
| Габдулхаков А.Р. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кадастр мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Сабирзянова А.М. | “Роскадастр” ППК директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Главы городского и сельских поселений | килешү буенча |
| Савельев В.П. | “Идел буе кадастр инженерлары Ассоциациясе” үз-үзен көләүче оешманың башкарма директоры (килешү буенча) |
| Валеев А.А. | “Идел буе” АКИ СРО вәкиле (килешү буенча) |
| Купоросова С. Н. | “СОКОЛ” коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәте рәисе (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
башкарма комитеты
Карарына
21.05.2025 ел, № 148
2нче Кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча Килештерү комиссиясенең эш регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча Килештерү комиссиясенең эш регламенты (алга таба – Регламент) “Кадастр эшчәнлеге турында” 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 221-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге регламент комплексллы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча Килештерү комиссиясенең (алга таба – килештерү комиссиясе) составын, вәкаләтләрен һәм эш тәртибен билгели.

1.3. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларына, шулай ук регламентка таяна.

1.4. Килештерү комиссиясенең эш максаты комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерүдән гыйбарәт. Чикләрнең урнашу урыны 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чикләренең урнашу урыны мәҗбүри килештерелергә тиешле җир кишәрлекләренә карата килештерелә.

## II. Килештерү комиссиясенең вәкаләтләре

2. Килештерү комиссиясе вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

2.1. Түбәндәге хокукта чиктәш җир кишәрлекләренә ия булган кызыксынучы затларның җир кишәрлекләренең чикләре урнашуга карата каршылыкларны карау:

1) милек (дәүләт яисә муниципаль милектәге мондый чиктәш җир кишәрлекләре гражданнарга гомерлек мирас итеп, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, яисә дәүләт яки муниципаль учреждениеләр булмаган юридик затларга, яисә казна предприятиеләренә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирелгән очраклардан тыш);

2) гомерлек мирас итеп;

3) даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану (мондый чиктәш җир кишәрлекләре дәүләт яисә муниципаль учреждениеләргә, казна предприятиеләренә,

дәүләт хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирелгән очраклардан тыш);

4) аренда (әгәр мондый чиктәш җир кишәрлекләре дәүләт яки муниципаль милектә булса һәм тиешле аренда шартнамәсе биш елдан артык вакытка төзелгән булса) (алга таба - кызыксынучы затлар);

2.2. Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затларның җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынына карата, шул исәптән мондый каршылыкларның нигезсезлеге очрагында территориянең карта-планы проектын үзгәртүнең максатка ярашсызлыгы турында яки башкаручы тарафыннан мондый каршылыклар нигезендә территориянең карта-планын үзгәртү кирәклеге турында каршылыкларны карау нәтиҗәләре турында килештерү комиссиясе бәяләмәсен әзерләү.

2.3. Комплексны кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашу урынын килештерү актын рәсмиләштерү.

2.4. Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затларга җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны турында җир бәхәсләрен суд тәртибендә хәл итү мөмкинлеге турында аңлату.

## III. Килештерү комиссиясе составы, килештерү комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләре

3.1. Килештерү комиссиясенең рәисе булып Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тора.

3.2. Килештерү комиссиясе рәисе:

3.2.1. Килештерү комиссиясе эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә.

3.2.2. Килештерү комиссиясе эшчәнлеген планлаштыра, килештерү комиссиясе утырышларының көн тәртибен раслый.

3.2.3. Килештерү комиссиясе утырышының көн тәртибендәге мәсьәләләрне карауны оештыра.

3.2.4. Карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне тавыш бирүгә куя, тавыш бирүне һәм килештерү комиссиясе әгъзаларының тавышларын санауны оештыра, аларның тавыш бирү нәтиҗәләрен билгели.

3.2.5. Килештерү комиссиясе исеменнән җибәрелә торган гарызнамәләргә, мөрәҗәгатьләргә һәм башка документларга имза сала.

3.3. Килештерү комиссиясе рәисе урынбасары рәис булмаганда рәис вәкаләтләрен башкара.

3.4. Килештерү комиссиясе сәркатибе:

3.4.1. Килештерү комиссиясе утырышларында карау өчен материаллар әзерләүне оештыра.

3.4.2. Килештерү комиссиясе утырышының көн тәртибе проектын формалаштыра.

3.4.3. Килештерү комиссиясе әгъзаларына утырышны үткәрү вакыты һәм урыны, утырышның көн тәртибе турында хәбәр итә, утырышка әзерләнгән материаллар белән таныштыра.

3.4.4. Килештерү комиссиясе утырышларының беркетмәләрен алып бара.

3.4.5. Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата каршылыкларны карау нәтиҗәләре турында килештерү комиссиясе бәяләмәсен,

комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашу урынын килештерү актын әзерли.

3.4.6. Килештерү комиссиясе рәисе яисә килештерү комиссиясе рәисе урынбасарының килештерү комиссиясе эшчәнлегенә бәйле башка йөкләмәләрен үти.

3.5. Килештерү комиссиясе әгъзалары:

3.5.1. Килештерү комиссиясе утырышларын әзерләүдә килештерү комиссиясе рәисе йөкләмәсе нигезендә катнашалар;

3.5.2. Килештерү комиссиясе утырышларында катнашалар;

3.5.3. Утырышта булмаган очракта карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен язма рәвештә бәян итәләр, ул утырышта игълан ителә һәм килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсенә кушып бирелә.

3.6. Утырышта кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта килештерү комиссиясе әгъзалары үз фикерләрен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсенә һичшиксез беркетелергә тиеш.

## IV. Килештерү комиссиясенең эш тәртибе

4.1. Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыннарын килештерү мәсьәләсе буенча комиссия утырышын үткәрү турында, шул исәптән территориянең карта-планы проектын әзерләү тәмамлану турында хәбәрнамәне үз эченә алган хәбәр комплекслы кадастр эшләре заказчысы тарафыннан күрсәтелгән утырыш уздырылган көнгә кадәр унбиш эш көненнән дә ким булмаган вакыт эчендә комплекслы кадастр эшләрен башкару башлану турында хәбәрнамәне бастырып чыгару, урнаштыру һәм җибәрү өчен Федераль законда билгеләнгән ысуллар белән бастырыла, урнаштырыла һәм җибәрелә.

4.2. Территориянең карта-планы проекты комплекслы кадастр эшләре заказчысы тарафыннан килештерү комиссиясенә 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы 9 өлеше нигезендә җибәрелә.

4.3. Килештерү комиссиясе теләсә нинди затларны территориянең карта-планы проекты белән таныштыруны түбәндәге юллар белән тәэмин итә:

4.3.1. Гариза бирүче соратуы буенча электрон документ формасында территориянең карта-планы проектын юллау.

4.3.2. Килештерү комиссиясенең урнашу урыны буенча документ формасында территориянең карта-планы проекты белән танышу мөмкинлеген бирү.

4.4. Килештерү комиссиясе утырышында территориянең карта-планы проекты тәкъдим ителә, комплекслы кадастр эшләрен башкару нәтиҗәләре, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыннарын килештерү тәртибе һәм килештерү комиссиясенең эш регламенты аңлатыла.

4.5. Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затларның җир кишәрлеге чикләренең 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.1 статьясы 1 өлеше 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән урнашу урынына карата каршылыклары килештерү комиссиясе утырышын уздыру турында хәбәр басылып чыккан көннән алып әлеге утырыш уздырылган көнгә кадәр, шулай ук килештерү комиссиясенең беренче утырышы узган көннән алып утыз биш эш көне эчендә килештерү комиссиясенә язма рәвештә тапшырылырга мөмкин.

4.6. Җир кишәрлегенең урнашу урынына карата каршылыклар 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы 15 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алырга тиеш. Билгеләнгән сроктан соң килгән каршылыклар килештерү комиссиясе тарафыннан каралмый. Әлеге каршылыкларны караудан баш тарту турында хәбәрнамә әлеге каршылыклар кергән көннән алып өч эш көне эчендә кызыксынучы затка җибәрелә.

4.7. Җир кишәрлеге чикләре яки өлешләренең урнашу урыннарын килештергәндә, мондый чикләрнең яки аларның өлешләренең урнашу урыны санала:

4.7.1. Килештерелгән дип, әгәр җир кишәрлеге чикләренең яисә өлешләренең урнашу урыны турында бәхәсләр Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затлар тарафыннан, шулай ук мондый чикләрнең яисә чик өлешләренең урыны законлы көченә кергән суд акты нигезендә билгеләнгән булса, шул исәптән җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны турында җир бәхәсе каралуга бәйле рәвештә, кызыксынучы затлар тарафыннан тапшырылмаган булса.

4.7.2. Бәхәсле дип, әгәр Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затлар тарафыннан җир кишәрлеге чикләренең яисә өлешләренең урнашу урынына карата каршылыклар бирелгән булса, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны турындагы җир бәхәсләре,суд тәртибендә рөхсәт ителгән очраклардан тыш.

4.8. Килештерү комиссиясенең эш нәтиҗәләре буенча килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 2015 елның 20 апрелендәге 244 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча төзелә, шулай ук җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата каршылыкларны карау нәтиҗәләре турында килештерү комиссиясе бәяләмәсе төзелә, ул үз эченә ала:

4.8.1. Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата кызыксынучы затлар каршылыкларының кыскача эчтәлеген.

4.8.2. Килештерү комиссиясенә тапшырылган материаллар турында мәгълүматны.

4.8.3. Килештерү комиссиясенең җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата кызыксынучы затларның каршылыкларын карау нәтиҗәләре буенча, шул исәптән мондый каршылыкларның нигезсезлеге очрагында территориянең карта-планы проектын үзгәртүнең максатка ярашсызлыгы турында яки башкаручының мондый каршылыклар нигезендә территориянең карта-планын комплекслы кадастр эшләрен үзгәртү кирәклеге турында нәтиҗәләрне.

4.9. Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашу урыннарын килештерү актлары һәм килештерү комиссиясенең Регламентның 2 бүлеге 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән бәяләмәләре килештерү комиссиясе утырышын уздырган көннән биш эш көне эчендә рәсмиләштерелә, алар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетында саклана.

4.10. Килештерү комиссиясе тарафыннан комплекслы кадастр эшләрен башкаручы тарафыннан территориянең карта-планы проектына үзгәрешләр кертү кирәклеге турында карар кабул ителгән очракта, кызыксынучы затларның җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата каршылыклары нигезле булу сәбәпле, беркетмә һәм бәяләмә имза куелганнан соң өч эш көне эчендә комплекслы кадастр эшләрен башкаручыга җибәрелә.

4.11. Территориянең карта-планы проекты ахыргы редакциядә комплекслы кадастр эшләрен башкаручы тарафыннан Регламентның 4.10 пунктында каралган документлар кергән көннән соң ун эш көне эчендә килештерү комиссиясе адресына җибәрелә.

4.12. 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы 14 өлешендә каралган каршылыкларны тапшыру вакыты чыккан көннән соң егерме эш көне эчендә килештерү комиссиясе комплекслы кадастр эшләренә заказ бирүчегә комплекслы кадастр эшләрен башкаручы тарафыннан рәсмиләштерелгән территориянең карта-планы проектын һәм аны раслау өчен кирәкле килештерү комиссиясе утырышы материалларын җибәрә.

4.13. Килештерү комиссиясе утырышлары кирәк булган саен үткәрелә.

4.14. Килештерү комиссиясе утырышы, әгәр анда килештерү комиссиясе әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

4.15. Килештерү комиссиясе карарлары утырышта катнашучылар саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Килештерү комиссиясе әгъзаларының тавышлары тигез булганда, килештерү комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

## V. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Җир кишәрлекләре чикләре урнашу турында 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясында каралган, аларга карата комплекслы кадастр эшләре башкарылган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыннарын килештерү нәтиҗәсендә җайга салынмаган җир бәхәсләре, комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашу урынын килештерү актын рәсмиләштергәннән соң суд тәртибендә хәл ителә.

5.2. Килештерү комиссиясе бәяләмәсенең булуы яки булмавы комплекслы кадастр эшләре башкарыла торган территориядә урнашкан җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны турында бәхәсләрне хәл итү өчен судка мөрәҗәгать итүгә комачауламый.

ПРОКУРАТУРА РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
ПРОКУРАТУРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**ПРОКУРАТУРА
АРСКОГО РАЙОНА**
Галактионова ул., 1, Арск, 422000

455886 668308

Руководителю исполнительного комитета Арского муниципального района Республики Татарстан

Гатиятову Р.М.

21.02.2025 №01-01-2025/111-25-20920009

Сообщаю, что прокуратурой Арского района рассмотрен представленный Вами проект постановления исполнительного комитета Арского муниципального района «О создании согласительной комиссии по согласованию местоположения границ земельных участков при выполнении комплексных кадастровых работ на территории Арского муниципального района Республики Татарстан».

Содержащиеся в проекте постановления нормы достаточны для достижения цели правового регулирования. Правила юридической техники соблюдены. Проект постановления не содержит коррупциогенных факторов. Нарушений требований федерального и республиканского законодательства не выявлено. Замечаний по рассмотренным проектам НПА не имеется.

И.о. прокурора района

младший советник юстиции Р.Н. Юсупов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат 0F7FE6F78E3060A4F0950A73242032C1
Владелец **Юсупов Рамиль Наилович**
Действителен с 22.01.2025 по 17.04.2026

Прокуратура Арского района Республики Татарстан
№ 01-01-2025/111-25-20920009